ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1755 2016 елның 30 декабре

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалануга түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта идарә итү, карап тоту һәм тиешле булмаган сыйфатта һәм (яки) билгеләнгән дәвамлылыктан арткан тәнәфесләр белән гомуми мөлкәтне ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында, торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, Россия Төзелеш министрлыгының «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалануга түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалануга (наемга түләү) түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмәне 2017 елның 1 гыйнварыннан расларга, гамәлгә кертергә (кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча, били торган торак урынны наемга алучы өчен, торак урынга түләү билгеләү турында» 2013 елның 25 декабрендәге 1971 номерлы карарының 6 пункты 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Нижнекамская правда» и «Туган як» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы Түбән Кама
муниципаль районы Башкарма комитетының
2016 елның 30 декабрендәге 1755 номерлы
карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарын наемга алуга түләү күләмен исәпләү турында Нигезләмә

1. Социаль наем шартнамәсе буенча яисә дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча бирелгән торак урынын наемга алган өчен түләү күләме 1 нче формула буенча билгеләнә:

1 нче формула

$П_н = Н_б * К_к * К_с * П$, кайда

Пн – социаль наем шартнамәсе буенча яисә дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынын наемга алган өчен түләү күләме;

Нб - торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме;

Кк - торак бинаның сыйфатын һәм төзекләндерелешен, йортның урнашу урынын характерлый торган коэффициент;

Кс – түләүнең туры килүе коэффициенты;

П – социаль наем шартнамәсе яисә дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынына наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынының гомуми мәйданы (кв. м).

Түбән Кама муниципаль районының барлык категория гражданнары өчен түләүнең туры килүе коэффициенты 0,1 күләмендә билгеләнә.

2. Торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме 2 нче формула буенча билгеләнә:

2 нче формула

Нб = СРс * 0,001, кайда,

Нб - торак урынны наемга алган өчен түләүнең база күләме;

СРс - социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннары наем шартнамәләре буенча бирелә торган дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыны урнашкан муниципаль берәмлектә икенчел торак базарында 1 кв.м га уртача бәя.

Икенчел торак базарында 1 кв.метрның уртача бәясе Федераль дәүләт статистика хезмәтенең территориаль органы мәгълүматлары буенча билгеләнә.

2017 елга Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт статистика хезмәтенең территориаль органы мәгълүматлары нигезендә икенчел базарда 1 кв. м торакның уртача бәясеннән чыгып исәпләнгән торак урынын наемга алган өчен түләүнең база күләме 56,51 сум/кв. м тәшкил итә.

3. Торак урынны наемга алган өчен түләү күләме торак урынының сыйфатын һәм төзекләндерелешен, йортның урнашу урынын тасвирлый торган коэффициентларны кулланып билгеләнә.

К1 коэффициенты түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К1 = \frac{Км + Ксв + Кпл}{3},$$

К1, К2, К3, Км, Ксв, Кпл, – таблицада күрсәтелгән коэффициентлар.

| Коэффициент | Кулланучылык үзлекләре | Коэффициент күрсәткече |
|---|---|---|
| Торак урыны сыйфатын характерлаучы коэффициентлар ($К_{1.}$) | | |
| $К_м$ | Диварларның материалы: | |
| | кирпеч, таш | 1,2 |
| | блоклы, эрепанельле | 1,0 |
| | катнаш яки агач | 0,5 |
| $К_{св}$ | Йортларны тапшыру сроклары | |
| | 1996 елдан | 1,2 |
| | 1975 елдан 1996 елга кадәр | 1,0 |
| | 1960 елдан 1975 елга кадәр | 0,6 |
| | 1960 елга кадәр | 0,4 |
| $К_{пл.}$ | Торак урынны планлаштыру: | |
| | яхшыртылган | 1,2 |
| | стандарт | 1,0 |
| | стандарт түгел (шул исәптән коммуналь, тулай торак һәм кунакханә тибында) | 0,5 |
| Торак бинаны төзекләндерүне характерлый торган коэффициент ($К_{2.}$) | | |
| | Торак бинаның төзеклеге: | |
| | - лифтсыз һәм чүп үткәргечсез | 0,8 |
| | - лифтлы һәм чүп үткәргечле | 1,0 |
| | - лифтсыз чүп үткәргечле | 1,0 |
| Йортның урнашу урынын характерлый торган коэффициент ($К_{3.}$) | | |
| | Урнашу урыны: | 1,0 |

Торак урын өчен Кк интеграль кыйммәте, аерым параметрлар буенча күрсәткечләрнең уртача үлчәнгән кыйммәте буларак, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_1 + К_2 + К_3$$
$$К_к = \text{-----------------},$$